**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

“09”июнь 2023 ел №86

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советының
«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы «Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль
берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләрен раслау турында»2013 елның
17 декабрендәге 74 номерлы карарына үзгәрешләр
кертү хакында

Россия Федерациясе Федераль законына туры килэ торган 29.12.2022 № 612-ФЗ «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацын һәм «Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү хакында «19.12.2022 № 541-ФЗ Федераль законның үз көчен югалтуын тану хакында», “Конкуренцияне яклау турында» Федераль законның 18_1 маддәсенә таянып Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советы КАРАР итте:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең “Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 17.12.2013 № 74 Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советының карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 27 статьяның 5 өлешендәге 5 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 5.1 пункты белән тулыландырырга:

«5.1. Әгәр мондый килешү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 маддәсендә каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше кыяфәтен килештерү»;

1.2. 28 статьяның 7 пунктында «башкарма документацияне алып бару составы һәм тәртибе» дигән сүзләрне алып ташларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Кама Тамагы

муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районының
Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районының
Олы Карамалы авыл җирлеге Советы рәисе
Э.И.Байдамшин